| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА СЕЛЕНГУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӘЛӘНГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| “14” октябрь 2025 ел | № 1 |

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 5 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка Сәләнгеш авылы, Гагарин урамы, 32нче йорт адресы буенча урнашкан Сәләнгеш авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында Колхоз урамы буенча 1-37 нче йорттан, Полевая урамы буенча 1-17 нче йорттан, Горький урамы буенча 1-25 нче йорттан, Гагарин урамы буенча 1-47нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2025 елның 5 ноябрендә 10 сәгать 30 минутка Сәләнгеш авылы, Гагарин урамы, 32нче йорт адресы буенча урнашкан Сәләнгеш авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегенең Сәләнгеш авылында Калинин урамы буенча 4-43нче йорттан, Овражная урамы буенча 1-72нче йорттан, Яшьләр урамы буенча 1-9нчы йорттан, Гагарин тыкрыгы урамы буенча 1-12нче йортларында яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Сәләнгеш авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.
4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Сәләнгеш авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, СВОда катнашучылардан, 90 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2026 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге башлыгы А.Н. Пинин